Хәзрәт вәгазе

# ГАЙБӘТ ТУРЫНДА БЕР ДӘРЕС



Аятьнең кыскача мәгънәсе: ”Үлгән туганыгызның итен ашауны кем яратыр икән? Сез андый эштән чиркәнмәссезме? Дин кардәшегез турында гайбәт сөйләү шундый ук бер начарлыктыр”.

Димәк, бу аятьнең аңлатуынча, хурлау һәм гайбәт сөйләү кешеләрнең акылын, кальбен, инсаниятен, выждәнын һәм миллилеген начарлыкка әйләндерә. Гайбәт - дошман һәм кире кешеләрнең күп куллана торган, иң начар бер коралыдыр. Үзен изге саначан кеше бу пычрак коралга мөрәҗәгать итмәс, ул гайбәт коралын кулланмас.

Танылган, мәшһүр бер кеше шулай дигән: ”Үземне, дошманыма гайбәт белән җәза бирүдән югары тотармын. Һәм ул сүзгә колак салмам. Чөнки гайбәт зәгыйфь, начар кешеләрнең коралыдыр”.

Гайбәт ул шундый нәрсә - гайбәт ителгән кеше аны ишетсә, ачуы килер, үпкәләр иде. Әгәр дөресен әйтсә, ул гайбәт була. Әгәр ялган сөйләсә дә гайбәт. Һәм яла ягу булыр. Бу инде икеләтә пычрак һәм начар бер гөнаһ булыр.

Гайбәтнең харам булмаган урыннары. Берсе - бер кешенең гаебен, хаксызлыгын төзәтү өчен, изге ният белән, ул кешене тәртипкә кертә торган кешегә әйтсәң - ярый. Мәсәлән, бер баланың гаебен аның атасы яки тәрбия итүчесенә әйтү.

Икенчесе. Бер кеше белән эш эшләргә теләгән икенче кеше, беренче кешенең ничеклеген беләсе килеп, синнән сораса, син: ”Ул кеше белән эшләмә. Ул кешедән сиңа зыян килер”, - дип әйтсәң, гайбәт булмас.

Өченчесе. Максаты, нияте мыскыллау һәм хурлау булмыйча, киресенчә, ул кешене таныту өчен сөйләнсә - ярый. Мәсәлән, нияте мыскыллау һәм хурлау булмыйча, киресенчә, ул кешене таныту өчен сөйләнсә - ярый.

Югарыдагы шушы очракларда, хаклык өчен, нәфескә өлеш бирмичә, бары тик файда булсын өчен гайбәт сөйләнсә, - ярый. Югыйсә, гайбәт, ут ничек утыннарны яндырып бетерә, шуның кебек гайбәт тә салих (изге) гамәлне ашап бетерер.

Әгәр гайбәт сөйләгән яки гайбәт сөйләгән вакытта үз ихтыярың белән тыңлаган булсаң, ул вакыт шундый доганы укы:

”Аллаһым, мине һәм гайбәт сөйләгән кешене гафу ит”. Соңыннан ул кешене очратсаң, ”Синең артында гайбәт сөйләдем, мине гафу ит!” - дип, ризалыгын сора.

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Мөхәррәм 2010 миләди йыл**
**1432 һижри йыл.**

| Мөхәррәм | Аҙна көндәре | Декабрь | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Шаршамбы | 7 | 7.55 | 9.25 | 13.30 | 15.21 | 16.51 | 18.21 |
| 2 | Кесе йома | 8 | 7.56 | 9.26 | 13.30 | 15.20 | 16.50 | 18.20 |
| 3 | Йома | 9 | 7.57 | 9.27 | 13.30 | 15.20 | 16.50 | 18.20 |
| 4 | Шәмбе | 10 | 7.58 | 9.28 | 13.30 | 15.20 | 16.50 | 18.20 |
| 5 | Йәкшәмбе | 11 | 7.59 | 9.29 | 13.30 | 15.19 | 16.49 | 18.19 |
| 6 | Дүшәмбе | 12 | 8.01 | 9.30 | 13.30 | 15.19 | 16.49 | 18.19 |
| 7 | Шишәмбе | 13 | 8.02 | 9.31 | 13.30 | 15.19 | 19.49 | 18.19 |
| 8 | Шаршамбы | 14 | 8.03 | 9.32 | 13.30 | 15.19 | 19.49 | 18.19 |
| 9 | Кесе йома | 15 | 8.04 | 9.33 | 13.30 | 15.19 | 19.49 | 18.19 |
| 10 | Йома | 16 | 8.05 | 9.34 | 13.30 | 15.19 | 19.49 | 18.19 |
| 11 | Шәмбе | 17 | 8.06 | 9.35 | 13.30 | 15.19 | 19.49 | 18.19 |
| 12 | Йәкшәмбе | 18 | 8.07 | 9.36 | 13.30 | 15.20 | 15.50 | 18.20 |
| 13 | Дүшәмбе | 19 | 8.08 | 9.37 | 13.30 | 15.20 | 16.50 | 18.20 |
| 14 | Шишәмбе | 20 | 8.08 | 9.38 | 13.30 | 15.20 | 16.50 | 18.20 |
| 15 | Шаршамбы | 21 | 8.08 | 9.38 | 13.30 | 15.21 | 16.51 | 18.21 |
| 16 | Кесе йома | 22 | 8.08 | 9.38 | 13.30 | 15.21 | 16.51 | 18.21 |
| 17 | Йома | 23 | 8.09 | 9.39 | 13.30 | 15.22 | 16.52 | 18.22 |
| 18 | Шәмбе | 24 | 8.09 | 9.39 | 13.30 | 15.22 | 16.52 | 18.22 |
| 19 | Йәкшәмбе | 25 | 8.09 | 9.39 | 13.30 | 15.23 | 16.53 | 18.23 |
| 20 | Дүшәмбе | 26 | 8.10 | 9.39 | 13.30 | 15.24 | 16.54 | 18.24 |
| 21 | Шишәмбе | 27 | 8.10 | 9.10 | 13.30 | 15.25 | 16.55 | 18.25 |
| 22 | Шаршамбы | 28 | 8.10 | 9.10 | 13.30 | 15.26 | 16.56 | 18.26 |
| 23 | Кесе йома | 29 | 8.10 | 9.10 | 13.30 | 15.27 | 16.57 | 18.27 |
| 24 | Йома | 30 | 8.10 | 9.10 | 13.30 | 15.28 | 16.58 | 18.28 |
| 25 | Шәмбе | 31 | 8.10 | 9.10 | 13.30 | 15.29 | 16.59 | 18.29 |

# ДӨНЬЯ БАЙЛЫГЫНА КЫЗЫКМА!

Барча хаталарның нигезе үзеңне дөнья тормышына гына бәйләүдә. Байлыкның файдалы ягын гына истә тотып, зарарын истән чыгарырга ярамый.

Беренче вазифа - байлыкның дәрәҗәсен аңлау.

Аллаһы Тәгалә Коръәннең кайбер аятьләрендә байлыкны мактый: ”Сезне мал белән һәм балаларыгыз белән куәтләр”, ә кайберләрендә хурлый: ”Белеп торыгыз, сезнең байлыгыгыз һәм балаларыгыз - фетнәдер”.

Чөнки, ахирәттә бәхеткә ирештерә торган ысул буларак, байлык якшы, ләкин ул Аллаһының зикереннән аера торган фетнәдер. Аның турында Раббыбыз болай дигән: ”Әй иман китергән бәндәләр! Сезне малларыгыз һәм балаларыгыз Аллаһ зикереннән аера күрмәсен”.

Икенче вазифа - керем һәм чыгымнар турында кайгырту.

Аларны тәртиптә тотарга кирәк. Бу вазифаның мактаулы ягы - зәкят-садакалар һәм галиләгә тоткан чыгымнар.

Яман ягының исә ике төре бар. Беренчесе: мал-дәүләтең күтәрә алмаслык буш чыгымнар. Икенчесе: кеше үз дәрәҗәсенә тиешле булган чыгымнар күләмен саранлыгы сәбәпле чикләве.

Өченче вазифа: көнкүреш (торыр җир, ашау, киенү) чыгымнарында уртача булу. Пәйгамбәребез (с.а.с.) әйткән: ”Тыныч йөрәк, сәламәт тән белән йокыдан торган, киләчәк көнгә ризыгы булган кеше дөнья тормышында ”бөтен нәрсәм бар”, - дип әйтә ала”.

Кешеләрнең иң хәерлеләре - урталыкны саклап, ике Йортка да (фани һәм мәңгелек) тиешлесен бирүчеләрдер. Алар бу юлда төрле куркынычларга очрап тәвәккәллек күрсәтәләр, һәм бөтен хикмәт тә шунда: югары дәрәҗәгә авырлыкларны җиңеп кенә ирешеп була.

Аллаһы Тәгалә әйткән: ”Сиңа Аллаһ биргән нәрсәләр ярдәмендә әхирәткә омтыл. Әмма, бу дөньядагы өлешеңне дә онытма! Сиңа Аллаһ изгелекләр кылган шикелле изгелекләр кыл һәм җир йөзендә бозыклык таратма”.

Гали разыяллаһу ганһү әйткән: ”Кеше җирдә булган бөтен нәрсәне Аллаһ ризалыгы өчен дип алса, нәфселегә саналмас. Моның өчен синең бөтен хәрәкәт һәм туктауларың Аллаһ ризалыгы өчен булсын.

Дөнья кеше өчен - кунакханә шикелле. Рәхмәт белән кабул итеп, җиңел йөрәк белән калдырыр өчен. Әмма, беркөнне, анда ахмаклар килеп, бу нәрсәләр аларга вакытлыча гына, әҗәткә генә бирелә дип түгел, ә бүләк рәвешендә, мәңгелеккә, дип белеп, тартып ала алмаслык рәвештә ябыштылар.

Тәртипне белүчеләр исә, кулланып, рәхмәт әйтеп, тыныч кына кире кайтаралар.

Җаны тыныч, тәне сәламәт, тамагы тук булганда кешенең дөньясы өчен кайгыга батып яшәве - ахмаклык билгесе.

Үткәннәре өчен булса, акыллы кеше өзелгәнне бәйләп, ватылганны ябыштырып, төзәтеп булмаганны белә. Монда инде берни дә эшләп булмый. Аллаһы Тәгалә дә әйткән: ”Җиргә дә, җаннарыгызга да бернинди хәвеф-хәтәр ирешмәс, моннан элегәрәк Китапта язылмаган булса. Хакыйкатьтә, бу Аллаһ өчен җиңел! Без моны, сез үткәннәрегезгә кайгырмас өчен һәм Аллаһ сезгә биргәннәрне өчен масаймас өчен ачтык. Аллаһ бит тәкәббер мактанчыкны сөйми”.

Хәзерге көн өчен башкаларга бирелгән дәрәҗә - байлыклары өчен була, моның сәбәбе - дөнья тормышын белмәү. Чөнки аны хакыйкатьтә белгән, аңлаган кеше үзен авыр йөк белән түгел, ә җиңел рәвештә баручылар җөмләсеннән кылган өчен Аллаһыга рәхмәтле.

Әгәр гашыйк кеше сөйгәнең матурлыклары ахырда нәрсәгә әйләнәчәкләре турында уйласа, әлбәттә, яратудан туктаячак.

Һәрбер кеше өч укның корбаны булырга мөмкин: бәхетсезлек, үч итү, үлем уклары. Алар үзара ярышып, кайвакытта тимиләр, кайвакытта максатка ирешәләр.

Кеше тәҗрибә буенча, һәр көнне кемдер үзе хуҗа булган нәрсәләрне югалтканын, дөньяда афәтләр булу сәбәпле, бәндәләр гел кайгыда булганнарын белсә, өч урынны зиярат кылган. Хастаханәгә барып авыруларның чир-михнәтләрен күргән. Һәм каберлеккә барып, кире кайтмас туганнары өстендә файдасыз күз яшьләрен түгүчеләргә карап кайта торган булган. Шуннан соң ул биргән рәхмәтләре өчен, көн дәвамында күргәннәре аңа ирешмәгән өчен Аллаһыга шөкерләр укый торган булган.

Һәр кеше дөньяда яшәгәндә шөкерле булыр өчен үзеннән түбәнерәккә карарга тиеш. Диндә исә - үзеңнән югарырак булганнарга карала, яхшылыкка омтылыр өчен. Шайтан исә, кешенең акылын буйсындыра алса, бу карашны барып-барып, капма-каршыга әйләндерә.

Киләчәктән курку ике төрле була. Котылыгыз нәрсәләрдән курку, мәсәлән, үлемнән. Бу - наданлык, чөнки ул бернәрсәгә дә карамастан бөтен кешеләргә дә ирешә. Ә инде куркуның сәбәбен бетерү мөмкин булса, яхшылап уйлап, төшенкелеккә бирешмичә, тәвәккәллек кылырга кирәк.

Кулыннан-көченнән килгәнне эшләгәч, Аллаһының әмерен-карарын тыныч йөрәк белән көтү тиешле. Мөэмин кеше Раббысының карарын, нинди булуына карамастан, ризалык белән кабул итеп ала.

Акыллы кеше, ныклап фикерләсә, йөрәген күп кайгылардан азат итә, әгәр йөрәге - сөйгән яры, мал, байлык, эш, дәрәҗә һ.б. - нык бәйләнмәгән булса.

Кешенең ике халәте бар: үлемгә кадәр һәм үлемнән соң.

Беренче халәттә кеше пәйгамбәребезнең сүзләрен ешрак искә аларга тиеш: ”Шатлыкларны юк итүчене (ягъни үлемне) еш истә тотыгыз”.

Үлемгә карата мөнәсәбәтләре буенча кешеләр ике төркемгә бүленәләр: Үлемнән гафилләр - алар фәкать балалары һәм калдырачак маллары турында кайгырып, җеназа намазын күргәч кенә: ”Без Аллаһыныкы һәм Аңа кайтачакбыз” - дип әйтүчеләр.

Әмма, гамәлләре белән алар Аллаһыга кайтмыйлар. Үлемгә игътибарлылар - болар аздан да канәгать булып, тәүбәгә ашыгучылар. Алар тиз үтүче тормышка нык ябышмыйлар һәм гыйбадәттә тырышлык күрсәтәләр.

Үлем халәтендә кешеләр төрле рәвештә булырлар.

Акыллы кеше тормыш аны әсирлектә тотканын, үлем - азат иткәнен аңлап, бу дөньяны үкенмичә калдыра.

Үлем хәлендә ятучы бер кешедән сораганнар: ”Ни өчен син курыкмыйсың һәм борчылмыйсың?” ”Чөнки мин элек йөрмәгән юлдан барам һәм Раббыма якынаям”, - дигән. Андый кешеләр үлемнән курыкмыйлар. Пәйгам-бәребез (с.а.с.) әйткән: ”Аллаһ белән очрашырга теләүче белән Аллаһ та очрашырга тели”.

Икенче кеше - аз акыллы, каралган йөрәкле, дөнья тормышына чумып баткан. Ул аңардан бик риза һәм тыныч. Ахирәт тормышы турында ул динсезләр кабер ияләре өчен кайтырганнары кебек кенә кайгыра. Әгәр ул дөнья нәҗесләреннән чыкса, Югарыгы Җәмәгать аны кабул итмәячәк. Андыйлар турында Аллаһ әйткән: ”Бу тормышта сукыр булган кеше ахирәт тормышында да сукыр булачак, башкалардан күбрәк читкә тайпылачак”.

Хакыйкатьтә беренчеләр дөнья тормышы - зиндан-төрмә, икенчеләр өчен - җәннәт. Беренчеләр хуҗасы чакырган кол шикелле, - ул аңа сөенеп бара, җавап бирә һәм, мөмкин кадәр яхшырак хезмәт итәргә тырыша. Икенчеләр исә, хуҗасына сөйрәп, бәйләнгән рәвештә китерелгән, качак кол шикелле, - ул хуҗасы алдында кылган җинаятенә үкенеп, башын аска төшереп, кимсенеп тора. Болар арасында нинди зур аерма!

Ә өченче төр кеше бу дөньяның хәсрәтләренә күнеккән, иялешкән кеше. Аны караңгы, пычрак өйдә яшәүче һәм аннан башканы күрмәгән кеше белән чагыштырып була. Өенә хәтта, керергә дә җирәнеп торса да, аны ташлый алмый.

Әгәр дә ки, ул аннан чыгып, Аллаһ хәерле бәндәләренә вәгъдә иткән нәрсәләрне күрсә, әлбәттә, элек калдырырга теләмәгән нәрсәләрне искә дә алмаячак, һәм әйтер: ”Безне кайгыдан коткарган Аллаһыга мактау! Хакыйкатьтә, Раббыбыз - Гафурур-Рахим. Ул, Үзенең рәхмәте белән безне, ару-талу ирешмәслек рәвештә Мәңгелек йортта урнаштырды”. ”Әгәр халыклар күрә тора залимгә ирек бирсәләр, аның кулларын кыскарту чараларына керешмәсәләр, Аллаһы Тәгаләнең газабы барына да төшәргә мөмкин”.